**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«19» 11 2025 ел Яр Чаллы ш. № 3831

ТР Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе – «Петушок» балалар бакчасы тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставының 29 статьясы 20 пункты, «Муниципаль мәгариф оешмалары хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» ТР Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 10 январендәге 4 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. ТР Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе – «Петушок» балалар бакчасы тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәт бәяләре прейскурантына кертелгән хезмәтләр бәясе хисабын 1 кушымта нигезендә расларга.
2. ТР Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе – «Петушок» балалар бакчасы тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәт бәяләре прейскурантына кертелгән хезмәтләр бәясе хисабын 2 кушымта нигезендә расларга.
3. Карарның гамәлдә булуы 2025 елның 01 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4. Әлеге карарны ТР Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
5. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 11 декабрендәге 5533 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны «ТР Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы вазыйфаларын башкаручы Э.Р. Низамиевага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л.Н. Маняпов

Муниципаль район Башкарма комитетының 2025 елның «19» 11. 3831 номерлы карарына 1 кушымта

2025 елның 1 октябреннән ТР Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе - «Петушок» балалар бакчасы буенча түләүле хезмәтләр күрсәтүгә бер тәрбияләнүчегә бәяләр прейскуранты

| № | Хезмәтнең исеме | Хезмәт бәясе (сум) | Хезмәт күрсәтү дәвамлылыгы |
|---|---|---|---|
| 1 | «Знайка» | 600,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 2 | «Бию» | 500,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |

2026 елның 1 гыйнвареннан

| № | Хезмәтнең исеме | Хезмәт бәясе (сум) | Хезмәт күрсәтү дәвамлылыгы |
|---|---|---|---|
| 1 | «Знайка» | 650,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 2 | «Бию» | 550,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |

ТР Тукай муниципаль районы
муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү
учреждениесе - «Петушок»
балалар бакчасы мөдире ____________ Р.Р. Гайфуллина

«Бюджет һәм казна учреждениеләренә хезмәт
күрсәтү үзәге» МБУ җитәкчесе урынбасары ____________ Р.Р. Йосыпова

ТР Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе - «Петушок» балалар бакчасы тарафыннан түләүле хезмәт күрсәтүгә бәяләр прейскурантына кушымта

1. **«Знайка»** - программа башлангыч мәктәптә укуга әзерлек формалаштыруны тәэмин итүгә, беренче сыйныф укучысының укуга уңышлы яраклашуын тәэмин итүче һәм мәктәпкә уңай мөнәсәбәт формалаштыручы интеллектуаль сыйфатларны, иҗади сәләтләрне һәм шәхес сыйфатларын үстерүгә юнәлтелгән.

Әлеге хезмәт 5 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге балаларга бирелә, кабинетның мәйданы 29,8 кв.м., балалар саны - 9. Атнага бер тапкыр.

2. **«Бию»** - программа балаларны бию сәнгатенә җәлеп итү, баланың хореография сәнгате ярдәмендә иҗади сәләтләрен ачыклау һәм ачу максатын куя.

Әлеге хезмәт 4 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге балаларга бирелә, кабинетның мәйданы 56,0 кв.м., балалар саны - 16. Атнага бер тапкыр.

ТР Тукай муниципаль районы муниципаль
бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе –
«Петушок» балалар бакчасы мөдире ____________ Р.Р. Гайфуллина

ДЕТСКИЙ САД "ПЕТУШОК"
ОГРН 1021601371835
ИНН 1639019448